**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы №41 03 октябрь 2016 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чемодурово авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чемодурово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге башлыгының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 14 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 38 номерлы карарын карап,

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чемодурово авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез Чемодурово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2017 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге зиратларны койма белән әйләндереп алу, территорияләрне чистарту, агачларны кисү һәм зиратлардан чыгару, гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме 68 мең сум күләмендә;

2) гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме 10 мең сум күләмендә тример сатып алу;

3) гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме 12 мең сум күләмендә территорияне җыештыру хезмәтләре күрсәтү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Н.Б. Котельникова